

Адәм баласынын сәләтенчә vз юнәлешендә тиешле югарылыкка кvтәрелvе - тырыш хезмәтенен жимеше. Һонәр сайлау, мина калса, язмыш сайлауга тин. Ул сина шатлык китерергә, син аннан ләззәт алырга тиеш. Үзен генә ләззәт алу да аз, Чын оста, Чын Кеше булыр очен, син vз эшен белән башкаларны да бәхетле итәргә бурычлы, менә шул вакытта син зур хөрмәткә лаек буласын. Авырлыклардан курыкмыйча эш яраткан, кулыннан эш килгән кешене бар да хормәт итә. Андый кешенен жирдә һәрвакыт vз урыны, vз юлы була.       Хормәткә лаек кешеләр бик кvп булган һәм бар. Бvген сvзебез шундый мәртәбәле шәхесләрнен берсе – Румия Халил кызы Донская хакында. Халыкка изгелек кылучы, бәхет-шатлык оләшvче Румия ханым олы рәхмәт сvзләренә лаектыр дип уйлыйм.

Румия Халил кызы Донская Кадошкино районында урнашкан «Чәчәкләр доньясы» жәмгыятьчелеге теплица комплексында ачылу коненнән бирле эшли. Кvп кенә гvзәл затларга чәчәкле матурлык бvләк итә. Нигездә, ир-атлар vзләренен икенче яртыларына, әниләренә, хезмәттәшләренә чәчәкләр һәм чәчәк бәйләмнәре тәкъдим итә. Ә аларны, нигездә, хатын-кызлар vстерә. Алар розаларнын чәчәк кибетләре киштәләренә эләгvендә турыдан-туры катнаша, ә аннары инде матур хужалар кулына да. Теплицанын чәчәк vстерvчесе Румия Халил кызы предприятие ачылуынын беренче эш конендә - 2006 елнын 28 ноябрендә килгән. Чәчәк vстерvче булып урнашканчы, ун ел Кадошкино автовокзалы кассасында эшләгән. «КЭТЗ» производствосы белән дә бераз таныш. Әлбәттә, Румия Халил кызына чәчәк vстерvче булып эшли башлагач, кvп нәрсәгә ойрәнергә туры килә. Чонки районда теплица хужалыгы әле ачылган гына була, беркайчан да мондый голчәчәкләр белән очрашырга туры килмәгән. Бу хәзер барлык процедуралар стандарт һәм гадәти булып тоела, ә баштан ук жинелләрдән булмаган. Һәр иртә чәчәк кисvдән башлана, аннары бокләv, жәю, vги бала табу. Ана Ред Наоми сортлы розаларнын ике секциясе беркетелгән чагы да булган. Ул игътибар белән vз участогын кvзәткән һәм тәрбияләп vстергән. Ә тагын Румия Халил кызы Донская чәчәкне сортларга аеру очен дә жаваплы. Rose Matic розаларын сортларга аеру машинасында эшләп, ул сортларга аерыла торган продукциянен тизлеген арттыруга һәм сатуга әзер сортланган чәчәкнен сыйфатын яхшыртуга да ирешә. Һәр чәчәк диярлек Румия кулы аша уза. Ул һәр розанын сыйфатына туры килvен игътибар белән кvзәтергә тиеш. Ә аннары инде машина-автомат рәвештә бу чәчәкне нинди букетта билгеләргә икәнен билгели - 50, 60, 70 сантиметр. Кыскасы, хаталар ясарга ярамый. Чонки кулланучыга чәчәк идеаль хәлдә, бер дефектсыз барып житәргә тиеш.



Ел саен Румия Халиловнага очәр укучы беркетелеп килгән: ул аларга vзенен тәжрибәсен һәм белемнәрен тапшырып, чәчәкләр белән дорес эшләргә ойрәткән.

Хәзерге вакытта аларга vз роза кишәрлекләре беркетелгән, анда яшь белгечләр югары житештерv кvрсәткечләренә ирешәләр.
Бvген Румия Халил кызы Донская vз эшчәнлеге юнәлеше буенча ин яхшы чәчәк vстерvчеләрнен берсе булып тора. Әлеге предприятиедә эшләгәндә vзен унай яктан кvрсәтеп килә. Житәкчелек һәм хезмәттәшләре анын хезмәт соючән, ярдәмчел булуын билгелиләр. Предприятие администрациясе тарафыннан бирелгән боерыкларны вакытында һәм сыйфатлы vти, зур коллективта абруй һәм ихтирам казана. Мордовиядә яшәгән һәм эшләгән Румия Халил кызы Донская, чәчәкләр бәйләменен матурларын vстергән тосле, унышларын да югары бәялиләр. «Чәчәкләр доньясы» жәмгыятьчелегендә намуслы һәм сыйфатлы хезмәте очен башта район житәкчесенен Рәхмәт хаты белән бvләкләнә, ә 2010 елда  Мордовия  Респуб-ликасы Главасынын Рәхмәтенә лаек була. 2015 елда Румия Халил кызы Донскаяга РМ Хокvмәтенен Мактау грамотасы тапшыралар.  Аннары намуслы хезмәте белән Россия Федерациясе Авыл хужалыгы министрлыгынын Рәхмәтен кабул  итә. Озакламый агросәнәгать комплексы системасында кvпьеллык намуслы хезмәте очен Румия Халил кызы Донская чираттагы югары бvләк - Россия Федерациясе Авыл хужалыгы министрлыгынын Мактау грамотасы белән бvләкләнә. 2026 нчы елнын 28 ноябрендә әлеге предприятиедә тырыш хезмәтенә 20 ел тула, ә хезмәт стажына - 44 ел!
Әйтеп китәргә кирәк, хезмәте югары бәяләнгән Румия Халил кызы шәхси тормышта да унган: Тагир Зиннур улы белән ике матур кыз тәрбияләп, югры белем биреп олы юлга лаеклы белгечләр буларак жибәрәләр. Ә Надия белән Гvзәлләре бvген әти-әниләре тосле хезмәттә хормәт казаналар – мактаулылар рәтендә. Оста хужабикә буларак, ашап туйгысыз пәрәмәчләр, кыекчалар, бәлешләр пешерә Румия ханым. Ойләрен, яз башлану белән бvгенге конгә кадәр, торле-торле чәчәкләргә кvмә: кайчан гына барысына да олгерә икән?!
Йомгак ясап бары шуны гына әйтәсе кала: нинди генә чорда яшәсәк тә, без намуслы хезмәт кешеләре булып кон итсәк, шул чакта барыр юлыбыз тигез була. Хезмәте барнын гына хормәте бар.

**Наилә НАСЫРОВА**